**Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе**
**«25 нче гомуми үстерешле балалар бакчасы»**

# Түбән Кама бакчалары һәм скверлары

Түбән Кама шәһәренең 10 мәктәбендә үткән «Компьютерная грамотность» Республика турнирында чыгыш- презентация.
Выступление- презентация в Республиканском турнире «Компьютерная грамотность», на базе школы №10, г.Нижнекамск.

Өлкән тәрбияче: Хузягалиева
Газимә Миннегали кызы

Түбән Кама. 2015

# *Түбән Кама бакчалары һәм парклары*



Түбән Кама. 2015

# ШӘҺӘР ЯМЕ - ПАРКЛАРДА

2015 ГОД ПАРКОВ И СКВЕРОВ В ТАТАРСТАНЕ

2015 ел – Татарстанда Парклар һәм скверлар елы дип игълан ителде. Бу елның үз логотибы бар. Әлеге елның төп максаты – экологик культура булдыру.

Логотипта заманча парк рәсеме. Паркка керә торган урында арка, агач эскәмия, фонарь, фонтан сурәтләнгән. Шулай ук кошлар һәм болыт образлары урын алган. Арткы фонда – ылыслы һәм яфраклы агачлар. Барлык фигуралар да яшел төснең 6 төсмере белән бизәлгән. Логотипта Сөембикә манарасы – Татарстанның милли төсмерен билгели, ә тимераяк һәм велосипед – республикабызның динамик үсешен күрсәтә, спорттагы уңышларына дан җырлый.

Логотип представляет собой стилизованное изображение современного городского парка, включающее в себя основные элементы — арку, деревянную лавку, фонарь, фонтан. Виды птиц и облака гармонично дополняют образ логотипа, подчеркивают важность парков как «зеленых легких» города. На заднем плане композиции изображены деревья хвойных и лиственных пород, являющиеся одновременно и единственным цветовым оформлением графической частилоготипа. Шесть оттенков зеленого цвета акцентируют тематику года и вместе с центральной фигурой — башней Сююмбике — привносят в логотип национальный колорит Татарстана.

# Лемаев мәйданы.



Туган якны Гомәр Бәширов яшел бишек белән тиңли. Чыннан да Түбән Кама яшеллеккә күмелгән. Шәһәребез бөтен табигать матурлыгын үз эченә сыйдырган. Шәһәр үзәгендә искиткеч матур урын бар. Бу - Лемаев мәйданы. Николай Васильевич Лемаев – “Түбән Кама нефтехим“ берләшмәсенең беренче генераль директоры. Аңа мәйданда һәйкәл куелган. Һәйкәл янында һәрвакыт чәчәкләр тора. Лемаев мәйданында “Җәлил” ял үзәге, кафелар бар. Кашкарый, лалә, петуния, кыңгырау чәчәкләре үскән түтәлләр янында рәхәтләнеп ял итәргә мөмкин. Матур фонтаннар мәйданга ямь өсти. Бу мәйданны олылар да, балалар да бик ярата.

# Җиңү мемориалы.



Октябрьнең 50 еллыгы урамында Җиңү мемориалы урнашкан. Бу монумент Бөек Ватан сугышында һәлак булган якташларыбыз истәлегенә куелган. Ул 1985 нче елда ачылган. Монументның авторы – архитектор Фирдәвес Ханов. Монумент янында мәңгелек ут яна. Мемориалдагы мәрмәр плитәләргә Бөек ватан сугышында һәлак булган якташларыбызның исемнәре язылган.

# “Д-29” гаубица пушкасы

Монумент янында,  Бөек Җиңүнең 60 еллыгы хөрмәтенә, Д-20" гаубица пушкасы куелган. Бу пушканы Мотовилихинск заводы эшчеләре бүләк иткән.



# “ИС-2” танкы.

Монумент янында,  шулай ук, ИС-2 (Иосиф Сталин-2) танкы куелган. Безнең шәһәребезгә Россия Армиясе Музее бүләк иткән. Бөек Ватан сугышында бу танкка тиңнәр булмаган




# Шәһәр паркы.

Шәһәр паркы Бакый Урманче урамындагы үзәк мәчет янында урнашкан. Анда төрле агачлар үсә: камырлыклар, каеннар.



# Тукай паркы.

Тукай паркында бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга һәйкәл куелган. Һәйкәлнең авторы – танылган татар скульпторы Бакый Урманче. 26 нчы апрель  - Габдулла Тукайның туган көне. Бу көнне һәйкәл янында шигырь бәйрәме үткәрелә.



# Скульптура «Су анасы»





## *Парки и скверы города Нижнекамск*

- **Сквер Лемаева. Лемаев бакчасы.**
- **Городской парк. Шәһәр паркы**
- **Парк аттракционов. Аттракционнар паркы.**
- **Парк имени Габдуллы Тукая. Тукай паркы.**
- **Парк нефтехимиков. Нефтехимиклар паркы.**
- **Школьный Бульвар. Мәктәп Бульвары.**
- **Место проведения городских праздников «Майдан». Мәйдан.**
- **Туристическая зона родника «Святой Ключ» на берегу Камы. Изге чишмә.**
- **Парк для семейного и спортивного отдыха «Солнечная поляна». "Кояшлы алан" паркы**
- **Аллея поколений. Киләчәк буыннар аллеясы.**